# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№4 30.11.2022 ел

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге Уртамак торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 30.11.2022 елдагы гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:«2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлеге Уртамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Россия армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Уртамак торак пунктында юлларның грейдерлау(килешү буенча түләү);

2) Уртамак торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (урам баскычлары кую, килешү буенча эш өчен түләү);

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 12 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 8 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенының 8 катнашучысы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар чыгарды:
1. Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегенең Уртамак торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга:«2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлеге

Уртамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән  хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Россия армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Уртамак торак пунктында юлларның грейдерлау(килешү буенча түләү);

2) Уртамак торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (урам баскычлары кую, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Николаевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлеге башлыгы урынбасарына Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: _______________ Липин.В.А
(имза)

Николаевка авыл җирлеге башлыгы урынбасары,
Совет рәисе _______________ Липин.В.А
(имза)